КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 27 декабрь г.Казань № 1169

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 май, 385 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1356 нчы; 2022 ел, 25 апрель, 393 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1468 нче; 2023 ел, 14 февраль, 143 нче; 2023 ел, 16 март, 260 нчы; 2023 ел, 15 декабрь, 1623 нче; 2024 ел, 11 март, 129 нчы; 2024 ел, 25 апрель, 277 нче; 2024 ел, 21 декабрь, 1180 нче; 2024 ел, 21 декабрь, 1181 нче; 2025 ел, 7 май, 302 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның өченче абзацында «гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган 2025 – 2027 елларда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проекты чараларын финанс белән тәэмин итү кагыйдәләренең 6 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«6. Министрлык әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгән акча исәбеннән түбәндәгеләргә субсидия бирүне гамәлгә ашыра:

социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүгә, шул исәптән озак вакыт карау системасы

кысаларында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итү өчен кирәкле чараларны гамәлгә ашыруга (тернәкләндерүнең техник чаралары прокаты пунктлары эшен оештыруны, ведомство мәгълүмат системалары базасында «Озак вакыт карау системасы» модулен булдыруны һәм тәэмин итүне кертеп);

социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә, шул исәптән карау буенча ярдәмчеләргә һөнәри белем бирү һәм һөнәри укыту, шулай ук өстәмә һөнәри белем бирү чараларын гамәлгә ашыруга;

өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга озак вакыт карау системасы кысаларында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның штат санын комплектлап бетерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруга.»;

әлеге карар белән расланган 2025 – 2027 елларда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының карауга мохтаҗ гражданнарга өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтүче «карау буенча ярдәмче» һөнәре буенча хезмәткәрләренең хезмәт хакын билгеләү үзенчәлекләре турындагы нигезләмәнең 2 пунктында:

икенче абзацта «21 200,0» саннарын «25 650,0» саннарына алмаштырырга;

җиденче абзацта «102» саннарын «78» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин